**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫМ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАР АР

№ 67

Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 31 августындагы 862 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 14 августындагы 569 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган су объектларында гражданнарның оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм кешеләрнең иминлеген тәэмин итүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетларының чыгымнары күләмен билгеләү методикасына 2 нче кушымтага үзгәреш кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2017 елның 28 декабрендәге 1064 номерлы карарын үтәү йөзеннән

КАРАР БИРӘМ:

1. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Гражданнар оборонасы» МКУ хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 31 августындагы 862 номерлы карарының 2 бүлегенең 4 пунктына үзгәрешләр кертергә, Нурлат муниципаль районы башкарма комитетының гражданлык оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, су объектларында кешеләрнең янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өлкәсендәге хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында, Нурлат муниципаль районы «Гражданнар оборонасы идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесенең вазыйфаи окладын билгеләп вазыйфаи бурычларын үтәгән һәм норматив эш фондын тиешле хисап чорында эшкәрткән өчен түләүне гарантияләргә.
2. Нурлат муниципаль районының «Финанс-бюджет палатасы» МКУ әлеге чараны финансларга.
3. Әлеге карар 01.01.2018 елдан үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге күрсәтмәнең үтәлешен тикшереп торуны Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин

**Килешенде:**
" Нурлат муниципаль районы Финанс - бюджет палатасы” МКУ рәисе

Сагирова Ф.В.

**Расланды:**
ТР Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе

Габдуллин Ә.К.

## ШТАТ РАСПИСАНИЕСЕ
## 2018 елның 1 гыйнварына «Нурлат муниципаль районы Гражданлык яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе

| **Вазыйфаларның атамасы** | **Штат берәмлекләре саны** | **Разряд** | **Вазыйфаи оклад** | **Барлыгы** |
|---|---|---|---|---|
| Учреждение директоры | 1 | 9 | 7 499,00 | 7 499,00 |
| Оператив кизү торучы | 4 | 8 | 6 823,00 | 27 292,00 |
| Барысы | 5 | | 14 322,00 | 34 791,00 |

«Нурлат
муниципаль районы гражданлык яклау идарәсе» МКУ директоры **БорһановН.М.**